Татарстан Республикасы

Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет майданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# Арча шәһәр Советы
# КАРАРЫ

«20» апрель 2026 ел

№ 23

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 17 сентябрендәге 134 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 9 номерлы үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Арча шәһәр Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының “Физик затлар мөлкәтенә салым турында” 2023 елның 29 ноябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 17 сентябрендәге 134 номерлы, 2025 елның 26 ноябрендәге 9 номерлы үзгәрешләр белән):

1.1. 2нче пунктта:

1.1.1. 5 пунктчаны 7 пунктча дип санарга;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) түбәндәгегә карата 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;»;

1.1.3. түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«6) түбәндәгегә карата 2,5 процент:

- проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;»;

1.2. 4нче пунктта:

1.2.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. дүрт һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);»;

1.2.2. өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге балалар, әлеге пунктның 4.1 бүлегендә күрсәтелгән физик затлар».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

"Арча шәһәре" муниципаль
берәмлеге Башлыгы в.б.
Арча шәһәр Советы рәисе в.б. Г.Х.Нигмәдҗанова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ГОРОД АРСК" АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРЧА ШӘҺӘР МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ *
ОГРН 1121690009220
«Совет города Арск»
ИНН 1609012685